# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 9.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2025 елда 600 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы :«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1. Карашай-Саклау торак пунктларын төзекләндерү ,халыкның күпләп ял итү урыннарын кору (Сабантуй милли бәйрәмен үткәрү урынын койма белән әйләндереп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу, «Хәтер бакчасы» паркын койма белән әйләндереп алу өчен әзер коймалар сатып алу ) ;
2. Карашай-Саклау авылындагы махсус күмү урыннарын төзекләндерү (биек агачларны йолкыту, куаклардан чистарту очен махсус аренда.техника яллау )
3. Карашай-Саклау торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;
4. Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыклары, чүп-чарлар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус техника яллау )

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 211 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 115 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 115 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2025 елда 600 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. Карашай-Саклау торак пунктларын төзекләндерү ,халыкның күпләп ял итү урыннарын кору (Сабантуй милли бәйрәмен үткәрү урынын койма белән әйләндереп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу, «Хәтер бакчасы» паркын койма белән әйләндереп алу өчен әзер коймалар сатып алу ) ;

2. Карашай-Саклау авылындагы махсус күмү урыннарын төзекләндерү (биек агачларны йолкыту, куаклардан чистарту очен махсус аренда.техника яллау )
3. Карашай-Саклау торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;
4. Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыклары, чүп-чарлар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус техника яллау )

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева